КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 30 декабрь г.Казань № 1281

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында төбәк контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2021 ел, 30 сентябрь, 935 нче карары белән расланган Автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру турындагы нигезләмәнең кушымтасына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында төбәк контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2021 ел, 30 сентябрь, 935 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 30 декабрь, 1339 нчы; 2023 ел, 11 ноябрь, 1464 нче; 2023 ел, 8 декабрь, 1582 нче; 2024 ел, 23 октябрь, 909 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру турындагы нигезләмәнең кушымтасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктта:

татар текстында «өч һәм аннан күбрәк» сүзләреннән соң «бер төрдәге» сүзләрен өстәргә;

«юл эшләрен башкару участогында яисә юл сервисы объектын урнаштыру зонасында» сүзләрен «юл сервисы объектын урнаштыру урынында» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле 3 пункт өстәргә:

«3. Юл эшләрен башкару участогында әлеге эшләрне башкару срогы дәвамында юл-транспорт һәлакәтләре тупланган урыннар барлыкка килү (юл шартларының канәгатьләндерерлек хәлдә булмавы сәбәп булып торган өч һәм аннан күбрәк бер төрдәге юл-транспорт һәлакәтләре кылыну).».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин